**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 май № 321

г. Казань

2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын үткәрү чорында Казан шәһәрендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм куллануны чикләү турында

Россия Федерациясенең «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукция кулланыны (эчүне) чикләү турында» 1995 ел, 22 ноябрь, ФЗ-171 нче Федераль законының 16 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын үткәрү чорында көчәйтелгән куркынычсызлык чараларын куллану үзенчәлекләре турында» 2017 ел, 9 май, 202 нче Указының 18 нче пункты нигезендә, 2017 елның 17 июненнән 2 июленә кадәр Казан шәһәрендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын үткәрүгә бәйле чараларның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:


1. 2017 елның 18, 22, 24, 28 июнендә Казан шәһәрендә «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукция кулланыны (эчүне) чикләү турында» 1995 ел, 22 ноябрь, ФЗ-171 нче Федераль законда күрсәтелгән, «ресторан» тибына кертелмәгән барлык ваклап сату объектларында, агызып сатыла торган сырадан һәм сыра эчемлекләреннән тыш, алкогольле продукция сату, шулай ук әлеге карарга теркәлгән 1 – 4 нче кушымталарда күрсәтелгән территорияләр чикләрендә алкогольле продукция куллану рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм килешү буенча Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 май, 321 нче
карарына 1 нче кушымта


«Казан Арена» стадионы




Түбәндәге урамнар чикләре: Әмирхан проспекты С.Хәким урамыннан Чистай урамына кадәр, Чистай ур. Адоратский урамына, Адоратский ур. Лаврентьев урамына кадәр, йорт территорияләре буйлап Лаврентьев ур. Гаврилов ур.,10 йортка кадәр, алга таба 3 нче транспорт дамбасының әйләнмә күпере чикләре буйлап («Мегастрой» кибетен кертеп) Троицкий лес урамына кадәр, Троицкий лес ур., алга таба Казансу елгасының су акваториясе кырые буйлап Әмирхан проспектына кадәр.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 май, 321 нче
карарына 2 нче кушымта

## «Казан-1» тимер юл вокзалы





Түбәндәге урамнар чикләре: Дзержинский ур. Пушкин урамыннан Лобачевский урамына кадәр, Лобачевский ур. Кремль урамына кадәр, Кремль ур. 1 Май мәйданына кадәр, Кремлевский спуск, Кремль диварлары буендагы юл, Кремль яр буе, тимер юл вокзалы мәйданын кертеп Сәетгалиев ур., Нариманов ур. Г.Камал урамына кадәр, Г.Камал ур. Г.Тукай урамына кадәр, Г.Тукай ур. Татарстан урамына кадәр, Татарстан ур. Пушкин урамына кадәр, Пушкин ур. Дзержинский урамына кадәр.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 май, 321 нче
карарына 3 нче кушымта

«Казан-2» тимер юл вокзалы





Түбәндәге урамнар чикләре: Ибраһимов проспекты (ике яклап йортлар) тимер юллардан Ак.Королев урамына кадәр, Ак.Королев ур. Мөхәммәдьяров урамына кадәр, Мөхәммәдьяров ур. тимер юлларга кадәр.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 май, 321 нче
карарына 4 нче кушымта

«Казан» халыкара аэропорты




Чикләр: аэропорт территориясе янындагы биналар.